Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Югары Акташ авыл Советы

КАРАР

14 декабрь 2023 ел № 86

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2021 елның 29 октябрендәге 27 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә

Югары Акташ авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1.Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2021 елның 29 октябрендәге 27 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл Советының 2023 елның 20 февралендәге 65 номерлы, 2023 елның 01 августындагы 78 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль хезмәткәрләргә классны чиннар бирү һәм муниципаль хезмәткәрләрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфаларына күчергәндә һәм муниципаль хезмәттән азат ителгәндә аларны саклап калу тәртибе» 4 бүлегендә карарга кушымталар:

- 4.6 пунктындагы 4.6.1 пунктчасында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

- 4.10 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

- 4.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турындагы карар, 4 бүлекнең 4.7 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлар белән классны чин бирү турында тапшыру кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Югары Акташ ав., Совет ур., 15 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Югары Акташ
авыл җирлеге башлыгы А.В.Шатунов